ГБМБУ «КФУ каршындагы 2 нче татар гимназиясе»
МБОУ «Татарская гимназия №2 при КФУ»

**КИЛЕШЕНДЕ**
Балалар бакчасы буенча
директор урынбасары:
________/ Р.Р. Шәрәфиева /
28.08.2020 нче ел

**РАСЛЫЙМ**
Директор:
______/ Р.Р.Гайнуллин /
Боерык №347
28.08.2020нче ел

Инглиз теле укытучысы
Әхмәтгалиева Миләүшә Рифатовнаның (югары кв. категория)
“Инглиз телен өйрәнәбез”
өстәмә белем бирү буенча
эш программасы

**СОГЛАСОВАНО**
Заместитель директора по ДГ:
_______/ Р.Р. Шарафиева /
28.08.2020 г.

**УТВЕРЖДАЮ**
Директор:
______/ Р.Р.Гайнуллин /
Приказ №347
от 28.08.2020 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учителя английского языка
Ахметгалиевой М.Р. (высшая кв.категория)
по дополнительной образовательной программе
“Изучаем английский язык”

Педагогик советта каралды

Беркетмә №1
28.08.2020 нчы ел

Рассмотрено на
педагогическом совете
Протокол №1
от 28.08.2020 г.

2020-2021 нче уку елы
2020-2021 учебный год

№23

**Аңлатма язуы.**

Р.Уотермен “Хәзерге эшлекле заманда үзгәрешләрдән дә даимирәк нәрсә юк”- дигән. Яңа стандартларга күчү барышында бала шәхесен күпкырлы үстерүдә, оештырылган белем бирү эшчәнлегендә дә, өстәмә белем бирү шөгыльләрендә дә төрле инновацияле технологияләр кулланыла. Балаларны үз илләрен яратучы көчле рухлы шәхесләр итеп тәрбияләү өчен шөгыльләр белән беррәттән өстәмә белем бирү эшчәнлегенең дә роле зур.

“Инглиз телен өйрәнәбез” эшчәнлеге буенча өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыру баланың иҗтимагый һәм шәхси яктан үсешенә, әйләнә-тирәне танып-белүенә бик нык ярдәм итә, аның хәзерге дөньяның күптеллелек һәм күп милләтлелегенә беренчел ияләшүне барлыкка китерә.

Программа мәктәпкәчә яштәге балаларны Л.Ф.Иванованың “Программа обучения английскому языку в дошкольном образовательном учреждении Республики Татарстан «First Steps in English» программасы нигезендә төзелгән. Программа мәктәпкәчә яштәге балаларга белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү шартларына җайлаштырылган һәм үзгәртелгән һәм Казан шәһәре Мәскәү районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Казан Федераль университеты каршындагы Ш.Мәрҗани исемендәге 2нче татар гимназиясе”нең мәктәпкәчә яштәге балалар өчен төркемнәрендә тормышка ашырыла.

Әлеге программаның педагогик яктан максатчанлыгы түбәндәгедән гыйбарәт: мәктәпкәчә яштәге балаларга инглиз телен өйрәтү, сүзләрне дөрес итеп әйтү, лексик запас җыю, чит телне ишетеп аңлауларын камилләштерү һәм авыр булмаган әңгәмәләрдә катнашасы килү теләге уяту.

Чит телне үзләштерү шәхеснең интеллектуаль, эмоциональ һәм әхлакый яктан үсеше белән тыгыз бәйләнештә булуы да мәктәпкәчә яштәге балаларга чит телне өйрәтүнең педагогик әһәмиятен ачыклый.

Белгечләр әйтүенчә, чит телне үзләштерү өчен иң кулай вакыт дип биш яшь санала. Психологлар бу яшьтә тел материалының җиңел истә калуын, фонематик ишетү сәләтенең югары дәрәҗәдә булуын ассызыклый. Хәтта чит телне өйрәнү вакытлыча туктатылып торса да, аны кечкенәдән өйрәнүне бушка вакыт әрәм итү дип санап булмый. Мәктәпкәчә яшьтә үзләштерелгән тел аеруча зур тизлек белән яңартыла дигән мәгълүмат бар.

**Актуальлеге.**

Тел-халыкның,милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе.

Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы- иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полингваль) шәхес тәрбияләү. Яшь барган саен телләр өйрәнүнең катлаулануын

шәхси тәҗрибәләреннән чыгып аңлаган өлкәннәр үз балаларына, баш миенең бөтен бер телләр блогын хәтергә салырга сәләтле чорында, телләр өйрәнү мөмкинлеге тудырырга омтылалар.Безнең бурыч- ата-аналарга әлеге теләкне тормышка ашырырга ярдәм итү,һәм бу эш, әлбәттә, балалар бакчасыннан башланырга тиеш. Бала тәрбияләүдә иң җаваплы чор- 7 яшькә кадәр, чөнки нәкъ менә шушы чорда сабыйларыбыз бар нәрсә белән кызыксына, аларның хәтер эшчәнлеге яхшы үсеш алган була. "Гомеребезнең беренче җиде елында, - дип язган күренекле рус педагогы К.Д.Ушинский, - безнең хәтеребез бөтен калган гомеребездә дә үзләштереп бетерә алмаслыкны үзләштерә". Хәзерге заманда телләр белү бик кирәк, ул безнең тормышыбызның аерылгысыз өлеше. Шулай итеп, безнең тикшерүнең актуальлеге җәмгыяттә һәм белем бирү өлкәсендә булган үзгәрешләргә нигезләнгән. Программаның актуальлеге шулай ук аның практик яктан әһәмияте белән дә бәйле. Балалар эшчәнлек барышында алган белем һәм күнекмәләрне мәктәпкә баргач та куллана алачаклар. Балалар бакчасында балаларда иң кирәклесе - телләр өйрәнүгә кызыксыну барлыкка киләчәк, ә бу үз чиратында мәктәптә инглиз телен өйрәнүгә бик нык ярдәм итә.

**Максат:** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны чит телдә гади җөмләләр кулланып аралашырга өйрәтү. Инглиз телен өйрәтү аша балаларны мәктәптә белем алуга әзерләү; аларның иҗтимагый, шәхси, танып белү күнекмәләрен, сөйләм телен үстерү өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

1.Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда чит телләрне өйрәнәсе килү теләге уяту, төрле телләргә карата кызыксынуларын булдыру; интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү.

2.Балаларны төрле телләрдә гади җөмләләр төзергә; гади үтенечләрне, боерыкларны аңлап үтәргә өйрәтү; гади сөйләм телен һәм туган телдәге сөйләм тәҗрибәсенә нигезләнеп,аралашу, коммуникатив осталыкларын үстерү.

3.Төрле телләрдә сөйләшүче халыкларның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәре белән таныштыру. Башка милләт халкына карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Программаның характерлы ( әһәмиятле ) үзенчәлеге** булып аның модификацияләнгән, ягъни үзгәртелгән булуы тора. Барлык үзгәрешләр Л.Ф.Иванованың "Программа обучения английскому языку в дошкольном образовательном учреждении Республики Татарстан «First Steps in English» программасын балалар бакчасында өстәмә белем бирү программасының шартларына яраклаштырып эшләнгән. Программа 1 елга гына исәпләнгән булу сәбәпле, кайбер темалар кыскартылды, сәгать саны кимеде.

Өстәмә белем бирү программасында темалар катлаулана бара, лексик материал, яңа грамматик формалар өйрәтелә. Балалар нормаль темп белән әйтелгәннең мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда куллана белергә өйрәнәләр. Сөйләм материалын истә калдыруны нәтиҗәле итү өчен- сөйләм структураларын кабат-кабат ишетү, ә тотрыклы ныгыту өчен даими кабатлау күнегүләре уздырыла. Инглиз теленең аваз төзелешен өйрәткәндә төп игътибар авазларны ишетә һәм аера, аларны дөрес итеп әйтә белү күнекмәләре булдыруга юнәлтелә. Бу бик әһәмиятле. Шуңа күрә һәр шөгыль башында фонетик күнегүләр уздырыла. Татарлар инглиз авазларын тизрәк һәм җиңелрәк әйтергә өйрәнә, чөнки инглиз телендәге *һ, ң, вау, къ, гъ* авазлары безнең телебезнең дә байлыгы булып тора. Шул ук вакытта басым, интонация аерымлыкларына да игътибар ителә.

Билгеле булганча, балалар тормышында уен зур урын алып тора. Шуңа күрә балаларны чит телләргә өйрәткәндә алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту өчен күп төрле уеннар ( сүзле, дидактик, сюжетлы, рольле,хәрәкәтле, һ.б.) уйнарга һәм аларны һәр шөгыльдә дә кулланырга кирәк. Сөйләм күнекмәләрен үстерү түгәрәк эшенең бердәнбер бурычы түгел. Моның белән янәшә баланың гомуми үсеше өчен шарт тудыруга зур әһәмият бирү зарур. Шөгыльдә рәхәт уен атмосферасы тудырып, тәрбияче балаларда уеннан укуга күчә торган активлык формалаштыра. Шөгыльләрдә ни дәрәҗәдә психологик рәхәтлек, иркенлек тудырылса, чит тел өйрәнү тизлеге шулкадәр зуррак, нәтиҗәлерәк була. Теләсә нинди киеренкелек баланың безнең белән аралашу теләген юкка чыгарырга, димәк, без өйрәтергә теләгән сөйләм материалының кулланышка керүенә киртә булырга мөмкин. Бала арымасын өчен акыл эшчәнлеге хәрәкәтләр белән үрелеп баруы, уен һәм биремнәрнең еш алмашынып торуы зарур. Шуңа күрә шөгыльләрдә балаларны өстәл артына түгел, ә паласка утырып шөгыльләнсәң отышлырак. Бу балаларга торып басу, хәрәкәтле уеннарда катнашуны да җиңеләйтә.

**Эшчәнлекнең вакыты һәм формалары:** программа *1 елга* исәпләнгән. Ул *32 шөгыльдән* тора (октябрь-май айлары). Шөгыльләр атнага бер тапкыр *30 минут* бара. Бу балаларның яшь үзенчәлекләрен истә тотып эшләнде. Шөгыльләрне оештыруның төп формасы -төркем белән эшләү.

## Көтелгән нәтиҗәләр:

1. Балалар инглиз һәм татар телләре белән күбрәк кызыксыналар; аларда чит телләрне өйрәнәсе килү теләге туа.

2. Балалар инглиз телендә гади җөмләләр төзергә; гади үтенечләрне, боерыкларны аңлап үтәргә һәм иптәшеңнең сорауларына җавап бирергә өйрәнәләр ( монологик һәм диалогик сөйләм). Шулай ук эшчәнлек барышында укытучының сөйләмен аңлый башлыйлар (аудирование).

3. Инглиз теленең авазларын дөрес әйтергә , басымны дөрес куярга тырышалар; авазларны татар һәм рус авазлары белән чагыштыралар; җөмләләрне дөрес интонация белән әйтәләр (фонетик күнекмә).

4. Үткән темалар буенча лексик минимумны беләләр; шигырьләр, җырлар, рифмовкалар сөйлиләр.

5. Инглиз телендә сөйләшүче халыкларның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәре турында белемнәре артты.

6. Балалар балалар бакчасында алган белемнәрен мәктәптә дә куллана алачаклар.

## Балаларга куелган таләпләр:

Балалар “Сәламләү”, “Танышу”, “Гаилә”, “Саннар”, “Хайваннар”, “Төсләр”, “Уенчыклар”, “Ел фасыллары”, “Ашамлыклар”, “Яшелчә. Җиләк-җимеш”, “Гәүдә өлешләре” кебек темаларның лексик эчтәлеген белергә тиеш.

**“Инглиз телен өйрәнәбез” түгәрәк эшенең тематик планы.**

| | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Сәламләү. | 2 |
| 2. | Танышу. | 1 |
| 3. | Гаилә. | 4 |
| 4. | Саннар. | 5 |
| 5. | Хайваннар. | 3 |
| 6. | Төсләр. | 3 |
| 7. | Уенчыклар. | 2 |
| 8. | Ел фасыллары. | 4 |
| 9. | Ашамлыклар. | 2 |
| 10. | Яшелчә. Җиләк-җимеш. | 3 |
| 11. | Гәүдә өлешләре. | 3 |
| Барлыгы | | 32 |

## Түгәрәк эшенең кыскача эчтәлеге

### Октябрь ае.

**1-нче атна.**

Тема: Без һәм инглиз теле .
Максат: Балаларга чит телләр өйрәнүнең әһәмиятен аңлату; аларга кеше тормышында инглиз теленең мөһимлеге, дөньядагы роле турында төшендерү. Лондон шәһәре, андагы истәлекле урыннар турында кыскача мәгълүмат бирү, рәсемнәр карау. Рифмовка "Hello", "Good morning…" (аудиоязма).
Яңа сүзләр:Good morning! Hallo! Good bye! Bye-bye!
Әдәбият: И.А.Мурзина.Урок №1. «Дошкольное воспитание»2003 ел №11(87-бит)

**2-нче атна.**

Тема: Инглиз телен өйрәнәбез!
Максат: Балаларны инглиз теленең роле белән таныштыруны дәвам итү; аларны бер-береңне бүлдермичә тыңларга өйрәтү; инглизчә шигырьләр һәм җырлар тыңлау; инглиз теленә карата мәхәббәт уяту. [ai], [ei], [au] авазлары өстендә эш.
Әдәбият: "English 2.Teacher's book" Верещагина,39 бит; И.А.Мурзина-Урок №2.

**3-нче атна.**

Тема: Әйдәгез,танышабыз!
Максат: My name is… структурасы һәм What is your name? соравы белән таныштыру;инглиз һәм татар теленең охшаш һәм аермалы якларын күрсәтү (сузык авазларның озынлыгы-кыскалыгы,h.б.) Уен " Исем уйла".( Балалар үзләренә башка исем уйлап, бер-берләре белән танышалар. "Good morning. My name is Jack."),сөйләм телләрен үстерү.
Яңа сүзләр: My name is… What is your name?
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",14-бит; " English.Teacher's book" Верещагина,40-бит.

**4-нче атна.**

Тема: Безнең гаилә.
Максат: Балаларны гаиләдәге кешеләр (mother,father,sister,brother)белән таныштыру. Алдагы шөгыльләрдә өйрәнелгән сөйләм үрнәкләрен,яңа структураларны сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен камилләштерү. Фонетик күнегү "Бал кортлары". [ ð ], [ ө ] авазлары өстендә эш. "Halloween" бәйрәме турында сөйләү, рәсемнәр күрсәтү.
Яңа сүзләр: mother,father,sister,brother.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",19-бит; Т.Н.Тележникова «Играя учим английский» (3-бит); Благовещенская «Первые уроки английского» (24-25 битләр)

## Ноябрь ае.

**1-нче атна.**

Тема: Әбием һәм бабаем!
Максат: Гаилә турында алдагы шөгыльләрдә өйрәнелгән сүзләрне ныгыту һәм яңа сүзләр белән таныштыру.( grandmother,grandfather) Әби-бабайларны хөрмәт итәргә,аларның сүзен тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Рифмовка тыңлау :"This is a mother".
Яңа сүзләр: grandmother,grandfather.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",19-бит; «English 2» Верещагина,22 бит.

**2-нче атна.**

Тема: Минем гаиләм.
Максат: "Гаилә" темасына кагылган барлык сүзләрне һәм конструкцияләрне яңа дидактик материаллар,уеннар,ситуатив һәм ишетеп аңлау күнегүләре аша ныгыту.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",19-бит; Т.Н. Тележникова «Играя учим английский» (3 бит); Благовещенская «Первые уроки английского» (24-25 бит)

**3-нче атна.**

Тема: I have got… I haven't got… структурасы.
Максат: I have got… I haven't got… структурасы белән таныштыру.Өйрәнелгән конструкцияләрне ныгыту;монологик сөйләм белән таныштыру;балаларны үзләре турында сөйли белергә һәм иптәшләренең гаиләсе турында сораша белергә өйрәтү. "Минем гаиләм" рифмовкасын сөйләп күрсәтү,балаларның рифмовка мәгънәсен мөстәкыйль аңлауларына ирешү.Гаиләдәге кешеләргә карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре тәрбияләү.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",15-бит; "700 английских рифмовок" Захарченко-34 бит (№1); "English 2" Верещагина (29-бит)

**4-нче атна.**

Тема: Без санарга_ өйрәнәбез.
Максат: 1 дән 3 кә кадәр булган саннар белән таныштыру;саннарны фонетик яктан дөрес итеп әйтүләренә ирешү,уенчык исемнәренең берлек һәм күплек саннарда ничек формалашуын аңлату.( one ball,two balls). [ o ], [ ə ], [ ʌ ] – авазлары өстендә эш.
Яңа сүзләр: one, two, three, ball, doll, cat, dog.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",15-бит; "English 2. Teacher's book." Верещагина,63 бит.

## Декабрь ае.

**1-нче атна.**

Тема: 4,5,6 саннары.
Максат: Карточкалар һәм уенчыклар ярдәмендә яңа цифрлар белән таныштыру,саннар белән килгән сүзләрнең берлектә һәм күплектә төрләнешенә игътибар итү (a dog-dogs) .Сүзләрне дөрес әйтү өстендә эш.
Яңа сүзләр: four, five, six.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",15-бит; "English 2" Верещагина,62 бит.

**2-нче атна.**

Тема: Без саныйбыз!
Максат: "One,two,three." рифмовкасы белән таныштыру; аны зарядка формасында башкару;уен барышында сүзләр һәм хәрәкәтнең туры килүенә ирешү. Алда өйрәнелгән материалны камилләштерү. Фонетик күнегү "Балыклар". [ w ], [ ts ] – авазлары өстендә эш.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",15-бит; English 2.Teacher's Book." 89 бит, "English 2" Верещагина,65 бит.

**3-нче атна.**

Тема: 7,8,9,10 саннары.
Максат: Яңа саннар белән таныштыруны дәвам итү; алда өйрәнелгән барлык саннарны яңа дидактик материаллар, уеннар, ситуатив һәм ишетеп аңлау күнегүләре аша кабатлау. "One,two,three" рифмовкасын искә төшерү, сөйләп күрсәтү. Җыр "My Fingers". Аудиоязмадан җырны тыңлау һәм бергәләп җырлау (1 little, 2 little, 3 little fingers…)
Яңа сүзләр: seven,eight,nine,ten.
Әдәбият: "English 2" Верещагина,65 бит.

**4-нче атна.**

Тема: Саннарны кабатлау.
Максат: 1-10 саннарын ныгыту; исемнәрнең күплек санда төрләнүләрен өйрәтүне дәвам итү. "Серле тартма", "Тәрҗемәче" дидактик уеннарын уйнау. [r] һәм [w] авазларын дөрес әйтү күнекмәләрен камилләштерү буенча эш оештыру. Яңа ел бәйрәменең Америкада, Англиядә һ.б. илләрдә ничек уздырылуы турында мәгълүмат бирү, рәсемнәр күрсәтү.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",15-бит; "English 2. Teacher's Book." Верещагина,65 бит.

## Гыйнвар ае.

**1-нче атна.**
Тема: Йорт хайваннары .
Максат: Рәсемнәр һәм уенчыклар ярдәмендә балаларны яңа лексика белән таныштыру, сүзләрне фонетик яктан дөрес әйтергә өйрәтү. Предмет-ларны, уенчыкларны санауны ныгыту. Фонетик эш : [ ʒ ], [ ou ], [ h ] авазлары.
Яңа сүзләр:a cow,a bull,a sheep,a pig,a horse.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",14-бит; Тележникова «Играя учим английский» ,5-6 бит.

**2-нче атна.**
Тема: Кыргый хайваннар .
Максат: Балаларны кыргый хайваннар белән таныштыру, яңа лексиканы дидактик материаллар, уеннар аша ныгыту. Предметларны санауны камил-ләштерү. Балаларның игътибарлылыкларын үстерү. Рифмовка өйрәнү "This is a bear…" Монологик сөйләм телләрен үстерү- "Минем уенчыгым".( Балалар өйләреннән алып килгән уенчык турында сөйлиләр. Мәсәлән: "Hello! My name is Amir. I have got a bear.")
Яңа сүзләр:a fox, a wolf, a hare ,a bear.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",14-бит; Тележникова «Играя учим английский» ,7-8 бит.

**3-нче атна.**
Тема: Хайваннар дөньясында.
Максат: Алдагы дәресләрдә өйрәнелгән лексиканы ныгыту,сөйләм телләрен камилләштерү, уйлау сәләтләрен,зиһеннәрен үстерү. Фонетик күнегү [ ei ], [ ai ] авазлары өстендә эш. Сөйләм телләрен баету максатыннан төрле уеннар уйнау. Пластилиннан хайваннар ясау һәм аларның күргәзмәсен оештыру. Һәр бала үзе ясаган хайванны тәкъдим итә: " I have got a crocodile."
Әдәбият: Тележникова «Играя учим английский».

**4-нче атна.**
Тема: Төсләр.
Максат: Төсле кәгазь һәм төсле карандашлар ярдәмендә яшел, сары, кызыл, зәңгәр төсләре белән таныштыру. Өйрәнелгән кострукцияләрдә төсләрне кулланып сөйләшә белергә өйрәтү.
Яңа сүзләр: green, yellow, red, blue.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",14-бит; "Дошкольное воспитание" 2003 ел,№12,7 задание,80 бит.

**Февраль ае.**

**1-нче атна.**
Тема: Ак, кара, көрән төсләре .
Максат: Яңа төсләр өйрәнүне дәвам итү; "Игътибарлы бул" , "Нинди төс?" һ.б. дидиактик уеннары һәм кубиклар белән уйнау ярдәмендә төсләрне сөйләмдә ныгыту. Фонетик күнегү [ w ], [ wai ] авазлары өстендә эш.
Яңа сүзләр: white, black, brown.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",14-бит.

**2-нче атна.**
Тема: Салават күпере .
Максат: Салават күперендәге төсләрне өйрәнү; "Салават күпере" , "Бу нинди төс?" дидактик уеннарын уйнау,уен аша төсләрне ныгыту. Салават күперен кәгазьдә ясау һәм буяу, краска һәм кисточкалар белән эшләү сәләтләрен камилләштерү. Төсләрне җөмләләрдә дөрес итеп кулланырга өйрәтү. "A Rainbow" рифмовкасын өйрәнү.
Яңа сүзләр: orange, purple.
Әдәбият: Благовещенская "Первые уроки английского" 12-13 бит; "English 2. Teacher's Book." Верещагина,69 бит.

**3-нче атна.**
Тема: Синең уенчыгың нинди?
Максат: Өйрәнелгән уенчык исемнәрен искә төшерү, берлек һәм күплек саннарның ничек ясалышы турындагы белемнәрен ныгыту, (a cat-cats_); сүзләрне дөрес итеп әйтүләренә ирешү. Уенчыклар темасына караган яңа сүзләр өйрәтү. Фонетик күнегү "Күп белергә теләүче куян". [ d ], [ t ], [ r ] –авазлары. Яңа сүзләр: a car, a plane, a flower.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",15-бит; Тележникова "Играя учим английский», 9 бит; Мещерякова «Я люблю английский» ,9 бит.

**4 нче-атна.**
Тема: Синең уенчыгың нинди? (дәвамы)
Максат: Балаларны яңа сыйфатлар белән таныштыру(зур, кечкенә, матур һ.б.) һәм аларны дөрес итеп әйтүләренә ирешү, фонетик күнегүләр үткәрү. Сюжетлы-рольле уен "Уенчык кибетендә"не уйнау аша күңелле кәеф булдыру.
Яңа сүзләр: big, little, nice, funny.
Әдәбият: Мещерякова «Я люблю английский» ,25 бит; «English 2. Teacher's Book» Верещагина,70 бит.

## Март ае.

**1-нче атна.**
Тема: Ел фасыллары .
Максат: Балаларны картиналар ярдәмендә ел фасыллары (кыш, яз, җәй,көз) белән таныштыру. Яңа сүзләрне фонетик яктан дөрес итеп әйтүләренә ирешү; алдагы шөгыльләрдә өйрәнелгән лексиканы камилләштерү. 8 нче март бәйрәме, "Mother's Day" бәйрәмнәре турында сөйләшү.
Яңа сүзләр: spring, summer, autumn, winter.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",21-бит; Тележникова «Играя учим английский» ,49 бит; Мещерякова «Я люблю английский», 19 бит.

**2 -нче атна.**
Тема: Мин яраткан ел фасылы.
Максат: Балаларны "Ел фасыллары" дигән рифмовка белән таныштыру, һәр ел фасылының үзенчәлекле билгеләрен күрә белергә өйрәтү; рифмовканы яттан өйрәнү. Фонетик күнегү [ ai ], [ ei] – дифтонглары өстендә эш.Төрле уеннар аркылы лексиканы ныгыту.
Әдәбият: Захарченко "700 английских рифмовок" , 72 бит.

**3-нче атна.**
Тема: Һава торышы.
Максат: Балаларны "Һава торышы" темасына караган яңа сүзләр белән таныштыру (a sun-sunny, a cloud-cloudy) . Һава торышы турында сөйләргә өйрәтү, җөмләләрне дөрес төзүләренә игътибар итү. ( It is sunny today. The sun is shining.) Саф һавага экскурсиягә чыгу, бүгенге һава торышы турында балаларның сөйләвен тыңлау.
Яңа сүзләр: sun, sunny, rain, cloud, cloudy, wind, windy, etc.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",21-бит; Тележникова "Играя учим английский» ,18 бит.

**4- нче атна.**
Тема: Без-рәссамнар.
Максат: Балалар белән "Һава торышы" һәм "Ел фасыллары" темаларын кабатлау, өйрәнелгән лексиканы ныгыту. Бирелгән темаларга карата рәсем ясау һәм үзләре ясаган табигать күренеше турында берничә гади җөмлә төзеп сөйләргә өйрәтү. Сөйләм телләрен баету;бер-береңне игътибар белән тыңларга өйрәтү.
Әдәбият: Мещерякова «Я люблю английский» , 17 бит.

**Апрель ае.**

**1-нче атна.**
Тема: Ашамлыклар.
Максат: Балаларны “Ашамлыклар” темасына кагылган яңа лексика белән таныштыру; сүзләрне фонетик яктан дөрес итеп әйтергә өйрәтү. “Give me...please”,“Here it is. ” конструкцияләре белән таныштыру. Фонетик күнегү [ t], [ch], [s]–авазлары өстендә эш.
Яңа сүзләр: bread, butter, cheese, sausage, biscuits, a cake.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова “Программа обучения английскому языку”,19-бит; Тележникова Т.Н. «Играя учим английский» , 27 бит.

**2-нче атна.**
Тема: Минем яраткан ризыкларым.
Максат: Алдагы түгәрәк эшендә өйрәнгән “Ашамлыклар” темасына кагылган сүзләрне ныгыту һәм яңа сүзләр өйрәтү. Балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен оештыру аша сөйләмне аңлау һәм инглиз телендә сөйләшәсе килү теләге уяту. Сюжетлы-рольле уен “Кибеттә”.
Яңа сүзләр: soup, macaroni, porridge, tea, coffee, sweets, ice-cream.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова “Программа обучения английскому языку”,19-бит; Тележникова «Играя учим английский» ,27 бит.

**3-нче атна.**
Тема: Яшелчәләр.
Максат: Балаларны кайбер яшелчәләрнең инглизчә ничек аталуы белән таныштыру. Алдагы түгәрәк эшләрендә өйрәнгән сөйләм үрнәкләрен, яңа лексиканы сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен камилләштерү. Фонетик күнегү [r ], [ t ], [ k ] –авазлары өстендә эш.
Яңа сүзләр: a cucumber, a tomato, a carrot, a potato, an onion.
Әдәбият: Т.Н. Тележникова «Играя учим английский» , 26 бит.

**4-нче атна.**
Тема: Җиләк-җимеш.
Максат: Балаларны җиләк-җимеш белән таныштыру. Яңа сүзләрне җөмләләрдә куллануны камилләштерү. Инглиз телендә сөйләшүченең сөйләмен тыңлый белүне формалаштыру, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышу,телне аз белүләренә карамастан, аның белән әңгәмәгә кереп, аралашырга омтылышын хуплау.
Яңа сүзләр: an apple, a banana, a cherry, an orange, a pear, a plum, grapes.
Әдәбият: Т.Н.Тележникова “Играя учим английский» ,25 бит.

## Май ае.

**1-нче атна.**
Тема: Өстәл янында.
Максат: Балалар белән "Ашамлыклар" темасына кагылган лексиканы төрле дидактик уеннар,ишетү күнегүләре аша камилләштерү. "Өстәл янында" сүзле уенын уйнау;инглизчә җөмләләр төзергә өйрәтү.( Give me an apple please.- Here it is.) Балаларның сөйләм телләрен баету. Өстәл янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшерү. Әвәләү "Минем яраткан яшелчәм(җиләк-җимеш)" Балалар үзләре яраткан яшелчәне әвәлиләр һәм презентациялиләр.
Әдәбият: Тележникова Т.Н. "Играя учим английский" ,28-29 бит

**2-нче атна.**
Тема: Баш һәм аның өлешләре.
Максат: Балаларны яңа лексика белән таныштыру,сүзләрне дөрес итеп әйтергә,ишетеп аңларга өйрәтү.
Яңа сүзләр: a head, a mouth, a nose, eyes, ears.
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",16-бит; Тележникова "Играя учим английский» ,21 бит, Благовещенская «Первые уроки английского» , 80 бит.

**3-нче атна.**
Тема: Гәүдә өлешләре.
Максат: "Гәүдә өлешләре" темасына караган яңа сүзләр белән таныштыруны дәвам итү һәм аларны сөйләмдә ныгыту. "Чисталык-сәламәтлекнең нигезе" әйтеменең мәгънәсенә төшендерү. Уен "Таркау рәссам", "Ә синдә?" аша сөйләм телләрен үстерү.
Яңа сүзләр: a body, a foot (feet ) , a hand (s) , a neck , a leg (s).
Әдәбият: Л.Ф.Иванова "Программа обучения английскому языку",16-бит; Тележникова «Играя учим английский» ,22 бит.

**4-нче атна.**
Тема: "Кем күбрәк белә?" (Викторина)
Максат: Ел буена өйрәнгән лексиканы, җөмләләрне һ.б. уеннар аша ныгыту,балаларның белемнәрен тикшерү,күңелле кәеф булдыру.